# Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы

# КАРАР

**№ 170** **«25» декабрь 2019 ел.**

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Югары Пәнәче авыл җирлеге генераль**
**планын раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 24, 25 статьялары нигезендә территорияне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү, гражданнар һәм аларның берләшмәләре мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьялары, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясы нигезендә, халык алдында тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлегенең Генераль планын расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе** **М.Х.Туктаров**